ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАМАДЫШ-ӘКИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2022 елның 16 февраль №67

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 27 апрелендәге 53 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советы
Карар:

1. Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында»2013 елның 27 апрелендәге 53 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтына урнаштырырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Мамадыш-Әкил авылы, Ленин урамы, 50 (администрация бинасы), Татар Танае авылы, Үзәк урамы, 1а (авыл мәдәният йорты бинасы), Паново авылы, Центральная урамы, 26в (авыл клубы бинасы)

Мамадыш-Әкил Авыл Җирлеге Башлыгы Ф.Ф. Мирхәтуллин